РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

2020 елның 7 мае Кукмара шәһәре № 284

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендә дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләрен һәм муниципаль милекне арендалаучыларга, реклама конструкцияләре хуҗаларына карата җаваплылык чараларын куллану үзенчәлекләре турында

Россия Федерациясе территориясендә яңа коронавирус йогышы (COVID-19) таралуга бәйле икътисадый хәл начарайган шартларда гражданнарга (шул исәптән шәхси эшмәкәрләргә) һәм оешмаларга ярдәм итү максатларында, Татарстан Республикасында әлеге авыру таралуга каршы тору максатларында кертелгән чикләү чараларын исәпкә алып, Кукмара муниципаль районы Советы **карар бирде:**

1. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль милкен (шул исәптән җир кишәрлекләрен) арендалаучылар һәм дәүләт милке чикләнмәгән һәм аларны бирү Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы җирле үзидарә органнары вәкаләтләренә кертелгән җир кишәрлекләрен арендалаучылар тарафыннан 2020 елның 1 апреленнән 30 июнен кертеп исәпләнгән аренда түләүләрен кертү буенча бурычларын (алга таба – аренда түләүләре) үтәмәгәндә (тиешенчә үтәмәгәндә), неустойкалар (штрафлар, пени), чит акчалардан файдаланган өчен процентлар һәм (яки) башка җаваплылык чаралары кулланылмый;

– Кукмара муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы белән реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләүгә килешү төзелгән Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы территориясендәге реклама конструкциясе хуҗалары тарафыннан 2020 елның 1 апреленнән 30 июнен кертеп исәпләнгән реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен түләүләр кертү буенча бурычларын (алга таба –

реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен түләүләр) үтәмәгәндә (тиешенчә үтәмәгәндә), неустойкалар (штрафлар, пени), чит акчалардан файдаланган өчен процентлар һәм (яки) башка җаваплылык чаралары кулланылмый;

- әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларында күрсәтелгән затлар тарафыннан аренда түләүләре һәм реклама конструкцияләрен урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен түләүләр кертү буенча бурычларын үтәмәгәндә (тиешенчә үтәмәгәндә), неустойкалар (штрафлар, пени), чит акчалардан файдаланган өчен процентлар һәм (яки) башка җаваплылык чаралары куллану 2020 елның 1 сентябреннән, күрсәтелгән датага кадәр чыккан чорны исәпкә алмыйча, яңадан торгызыла.

2. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Район Башлыгы Димитриев С. Д.